ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

“ 12 ” апрель 2016 ел № 431

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Арча муниципаль районында реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукы турында» 2015 елның 07 декабрендәге 1199 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Реклама турында" 2006 елның 22 февралендәге 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 ст. 5 нче өлешен үтәү максатларында. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында" 2013 елның 30 декабрендәге 939 номерлы карары нигезендә Арча район башкарма комитеты карар бирә:

1) Арча муниципаль районындагы реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамәләр төзү хокукына ачык аукционнарны әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәнең 3.5 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукын түләгән сатулар җиңүчесе күрсәтелгән килешүне төзергә һәм таләп ителә торган рөхсәт документациясен билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерергә тиеш. Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә (әлеге Нигезләмәгә кушымта) заказчы белән сатулар җиңүчесе арасында биш елга төзелә".

2) Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:\pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы З.З.Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.О.Галимуллин